**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Казан шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәренең Колсәет торак массивындагы «Солнечный» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Казан шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2020 елның 11 июлендәге ПУ-393 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 14 сентябрь
№ ПУ-577